Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
Бишмунча авыл Советы

КАРАР

24 апрель 2023 ел №69

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунчан авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында»2012 елның 27 декабрендәге 57 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлеше, Әлмәт муниципаль районының «Бишмунча авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләргә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләреннән бер өлешен тапшыру турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2022 елның 12 декабрендәге 182 номерлы карары, «Ачык тыңлауларны билгеләү турында» Әлмәт муниципаль районы Башлыгының 2023 елның 3 февралендәге 15 номерлы карары нигезендә узган 2023 елның 20 февралендәге 1378и номерлы ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр («Альметьевский вестник» газетасында басма, 2023 ел, 22 февраль, № 8) нигезендә

Бишмунча авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 27 декабрендәге 57 номерлы карарына (2022 елның 3 июнендәге 48 номерлы, 2022 елның 28 сентябрендәге 48 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 4 статьяның 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктча өстәргә:

«2.1) капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелешенә карата таләпләр;»;

- түбәндәге эчтәлекле 13.1 статья өстәргә:

«13.1 статья. Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелешенең тышкы күренеше.

1. Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелешенең тышкы күренеше, әлеге статьяның 2 өлешендә каралган очраклардан тыш, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 30 статьясындагы 5 өлешендә каралган территорияләр чикләрендә капиталь төзелеш объектын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда җирле үзидарәнең вәкаләтле органы белән килештерелергә тиеш.

2. Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелешенең

тышкы күренешен килештерү түбәндәгеләргә карата таләп ителми:

1) шәһәр төзелеше Регламентының гамәлдә булуы аларга кагылмый торган җир участокларында урнашкан капиталь төзелеш объектлары;

2) төзү яисә реконструкцияләү өчен төзелешкә рөхсәт алу таләп ителми торган объектлар;

3) җәзаларны үтәүче учреждениеләр файдалануындагы җир кишәрлекләрендә урнашкан объектлар;

4) Оборона һәм иминлек объектлары, Россия Федерациясе Кораллы көчләре объектлары, башка гаскәрләр, хәрби формированиеләр һәм дәүләт оборонасы һәм иминлеге өлкәсендәге функцияләрне гамәлгә ашыручы органнар;

5) Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән башка объектлар.

3. Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелешенең тышкы күренешен килештерү срогы ун эш көненнән артмаска тиеш.

4. Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелешенең тышкы күренешен килештерүдән баш тарту өчен, капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелешен билгеләүче һәм проект документларында яисә төзүче яки капиталь төзелеш объектын проектлауга техник заказчы биремендә, шәһәр төзелеше регламентында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелешенең тышкы күренешенә карата таләпләргә туры килмәве нигез булып тора.

5. Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелешенең тышкы күренешен килештерү тәртибе, әгәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелешенең тышкы күренешенә таләпләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында башкасы каралмаган булса, капиталь төзелеш объектының күләм-пространство, архитектура-стилистик һәм башка характеристикаларына карата таләпләрне үз эченә ала.»;

- 16 статьяның 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Җәмәгать фикер алышулары яисә ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр аларны уздыру турында муниципаль берәмлек халкына хәбәр иткән көннән алып муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм үндүрт көннән дә ким һәм утыз көннән дә артыграк була алмый.»;

- 21 статьяга түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12. Муниципаль берәмлекләр чикләрендә урнашкан Ватанны саклаганда һәлак булганнарны күмү урыннарын ачыклауга бәйле рәвештә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү мондый урыннар ачыкланган көннән алып алты ай дәвамында гамәлгә ашырыла, шул ук вакытта иҗтимагый фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар уздыру таләп ителми.»;

- 23 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3.1 һәм 3.2 пунктлар өстәргә:

«3.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында территорияне комплекслы үстерү күздә тотыла торган территорияләр мәҗбүри тәртиптә

билгеләнә. Мондый территорияләрнең чикләре бер яки берничә территориаль зона чикләрендә билгеләнә һәм аерым картада күрсәтелә ала. Мондый территорияләргә карата территорияне комплекслы үстерү турында бер яисә берничә шартнамә төзелә.

Территорияне комплекслы үстерү буенча эшчәнлек алып баруны күздә тоткан территорияләр «Бишмунча авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрендә билгеләнмәгән, шуңа бәйле рәвештә әлеге кагыйдәләр материалларында күрсәтелмәгән.

3.2 Шәһәр төзелеше зоналаштыру картасында чикләрендә капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелешенең тышкы күренешенә таләпләр каралган территорияләр күрсәтелә. Мондый территорияләрнең чикләре территориаль зоналар чикләре белән туры килмәскә мөмкин һәм аерым картада күрсәтелергә мөмкин.

Капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелешенең тышкы күренешенә таләпләр каралган территорияләр «Бишмунча авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрендә билгеләнмәгән, шуңа бәйле рәвештә әлеге кагыйдәләр материалларында күрсәтелмәгән.»;

- 26 статьяда:

-«Әлеге таблицада җайга салынмаган күрсәткечләр Техник регламентлар, СНиП, СанПиН һәм башка норматив документлар таләпләре нигезендә билгеләнә» абзацыннан соң түбәндәге абзацлар өстәргә:

«Шәһәр төзелеше регламенты тарафыннан билгеләнгән җир кишәрлекләренең чик (минималь) күләмнәре кулланыла алмый:

- шәхси милектә булган җир кишәрлеген һәм дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү юлы белән җир кишәрлеген булдыру һәм җирлектә мәйданы җир кишәрлекләренең чик (минималь) күләменә туры килгән җир кишәрлеген формалаштыру мөмкинлеге булмау;

- җир кишәрлеге ике һәм аннан да күбрәк җир кишәрлекләрен берләштерү юлы белән төзелү;


- гамәлдәге күчемсез милек объекты астында төзелә торган җир кишәрлеге барлыкка килү һәм мәйданы җир кишәрлекләренең иң чик (минималь) күләменә туры килә торган җир кишәрлеген төзү мөмкинлеге булмау»;


-Бишмунча авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертергә:

-табигый ландшафтларның территориаль зонасын (Р1) киметү һәм авыл хуҗалыгы җирләре зонасын (СХ1) билгеләү:

Гамәлдәге хәл


Проект тәкъдиме








Гамәлдәге хәл


Проект тәкъдиме












- кадастр номерлары 16:07:300003:801, 16:07:300003:1340, 16:07:300003:1339: булган җир участокларына карата табигый ландшафтларның территориаль зонасын киметү (Р1) һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә агросәнәгать комплексы объектларын урнаштыру зонасын билгеләү (СХ2):

Гамәлдәге хәл

Проект тәкъдиме




2. Әлеге карарны Бишмунча ав., Совет ур.,57 А й., Кама-Елга ав., Кама-Елга ур., 26, Ак-Чишмә ав., Ак-Чишмә ур. 1 й., Бахчасарай бис., Земляничная ур, 1 й. торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бишмунча авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Бишмунча авыл
җирлеге башлыгы

Р.Г.Фазлиев